**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

20 декабрь 2023ел.　　　　　　　　　　№ 39

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башлыгының 08.10.2019 №46 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының наркотикларга каршы комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында наркотикларга каршы комиссия турындагы Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башлыгының 08.10.2019 №46 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзен “Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алыштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 5 пунктындагы 6 пунктчасында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзен “Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башлыгы урынбасары Ф. М. Нуриевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль район башлыгы　　　　　　　　　　Г.Г. Хәкимов